**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**20.08.2021** **№ 724**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 05 февралендәге 151 номерлы «2021-2023 елларга Биектау муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 03 июнендәге 1053-р номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, спорт төрләре буенча спорт әзерлегенә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча муниципаль йөкләмәләрне муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс белән тәэмин итү максатларында, күрсәтелгән учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә башка бюджетара трансфертлар бүлү турында, һәм турында 2021 елның 09 июнендәге 1100-р номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тәэмин итүгә бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, түбә астындагы йөзү бассейнының оператив идарәсе хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә, Биектау муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансферлар бирү турындагы күрсәтмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 05 февралендәге 151 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Биектау муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программаның паспортында:

«Программаны финанслау чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау чыганаклары | 2021-2023 елларга Программаны финанслау күләме 147508,8726 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2021 ел – 46823,5126 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм 5937,960 мең сум республика бюджеты акчалары исәбеннән;<br>2022 ел – 47168,7 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән;<br>2023 ел – 47578,7 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән.<br>Ярдәмче программа-1не финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәллек кертелергә тиеш.<br>Республика бюджеты акчалары күләме, бюджеттан тыш чыганаклардан ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |

»

1.2. Программаның «ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕҢ НИГЕЗЛӘМӘСЕ» дип аталган III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2021-2023 елларга Программаны финанслау күләме 147508,8726 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2021 ел – 46823,5126 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм 5937,960 мең сум республика бюджеты акчалары исәбеннән;

2022 ел – 47168,7 мең сум;

2023 ел – 47578,7 мең сум.

Ярдәмче программа-1не финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәллек кертелергә тиеш.

Республика бюджеты акчалары күләме, бюджеттан тыш чыганаклардан ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

1.3. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына Кушымтаның 2 нче пунктын 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.4. «2021-2023 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү» ярдәмче программасы (алга таба - Ярдәмче программа-2) паспортында:

«Ярдәмче программа-2не финанслау чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| | |
|---|---|
| Ярдәмче | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы |

| | |
|---|---|
| программа-2не финанслау чыганаклары | бюджеты акчалары исәбеннән 2021 - 2023 елларда Ярдәмче программа-2не финанслауның гомуми күләме 139089,4536 мең сум һәм республика бюджеты акчалары исәбенннән 5937,960 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2021 ел – 45996,3596 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм 5937,960 мең сум республика бюджеты акчалары исәбеннән;<br>2022 ел – 46341,547 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән;<br>2023 ел – 46751,547 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән.<br>Ярдәмче программа-2не финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәллек кертелергә тиеш.<br>Республика бюджеты акчалары күләме, бюджеттан тыш чыганаклардан ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

»

Ярдәмче программа-2нең «ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММА-2НЕ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ» дип аталган III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2021 - 2023 елларда Ярдәмче программа-2не финанслауның гомуми күләме 139089,4536 мең сум һәм республика бюджеты акчалары исәбенннән 5937,960 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2021 ел – 45996,3596 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән һәм 5937,960 мең сум республика бюджеты акчалары исәбеннән;

2022 ел – 46341,547 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән;

2023 год – 46751,547 мең сум җирле бюджет акчалары исәбеннән.

Ярдәмче программа-2не финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәллек кертелергә тиеш.

Республика бюджеты акчалары күләме, бюджеттан тыш чыганаклардан ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк».

1.5. «2021-2023 елларга югары казанышлар спортын үстерү һәм спорт резервын әзерләү» ярдәмче программасына 1нче кушымтадагы «Физкультура-спорт эшчәнлеген финанс, матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын камилләштерү һәм аны оештыруның яңа формаларын гамәлгә кертү» 1 нче бурычын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми

сайтына: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 20 августындагы
724 номерлы карарына

**«2021-2023 ЕЛЛАРГА БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТНЫ ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ЧАРАЛАР БУЕНЧА ФИНАНСЛАУ**

| № п/п | Наименование подпрограммы | Исполни-тель (по согласова-нию) | Срок вы-пол-не-ния | Ис-точник финан-сирова-ния | Индикаторы оценки конечных результатов, единицы измерения | Индикатор билгеләре | | | | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2020 (база) | 2021ел | 2022ел | 2023 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | Барысы |
| | Максатның исеме: Биектау муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | |
| 2. | 2 нче бурычның исеме: Спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү һәм Биектау районы спортчыларының Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составында республика, төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларын тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| 2.1 | «2021 - 2023 елларга югары казанышлар | ЯЭСБ, МБ, ҮРХ, | 2021-2023 | ҖБ | Татарстан Республикасы спорт җыелма | 14 | 17 | 21 | 25 | 45947,347 | 46341,547 | 46751,547 | 139040,441 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2 | спортын һәм спорт резервын әзерләүне үстерү» | СМ | 2021 | РБ | командаларына кандидатлар исемлекләренә кертелгән спортчылар саны, кеше | | | | | 361,4 | - | - | 361,4 |
| 2.3 | | | 2021 | РБ | | | | | | 675,3 | | | 675,3 |
| 2.4 | | | 2021 | РБ | | | | | | 329,760 | - | - | 329,760 |
| 2.5 | | | 2021 | ЖБ | | | | | | 3,2976 | - | - | 3,2976 |
| 2.6 | | | 2021 | РБ | | | | | | 4571,5 | - | - | 4571,5 |
| 2.7 | | | 2021 | ЖБ | | | | | | 45,715 | - | - | 45,715 |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | | | | | 52761,4726 | 47168,7 | 47578,7 | 147508,8726 |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 20 августындагы
724 номерлы карарына

**«2021 - 2023 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү»**
**Ярдәмче программасын гамәлгә ашыру чаралары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

| № т/б | Чаралар | Башкаручы (килешү буенча) | Башкару срогы | Финанслау чыганагы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор билгеләре (фараз) | | | | Еллар буенча чыгымнар суммасы (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2020 (база) | 2021 | 2022 | 2023 | 2021 | 2022 | 2023 | Барлыгы |
| | **Максатның исеме: Физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру** | | | | | | | | | | | | |
| 1. | 1 нче бурычның исеме: Физкультура-спорт эшчәнлеген финанс, матди-техник һәм кадрлар белән тәэмин итү механизмнарын камилләштерү һәм аны оештыруның яңа формаларын гамәлгә кертү | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | Ведомство буйсынуындагы спорт мәктәпләрен һәм ведомство буйсынуындагы спорт корылмаларын карап тоту һәм | ЯЭСБ, СМ, СК | 2021-2023 | ЖБ, агымдагы финанслау | - | - | - | - | - | 45204,015 | 45598,215 | 46008,215 | 136810,445 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аларның эшчәнлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| 1.2 | Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү | СМ | 2021 | РБ | - | - | - | - | - | 361,4 | - | - | 361,4 |
| 1.3 | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруга һәм | «Биек тау» СМ | 2021 | РБ | - | - | - | - | - | 675,3 | - | - | 675,3 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль спорт мәктәпләре спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм (яисә) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А төркемчәсе) катнашуына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү | | | | | | | | | | | | |
| 1.4 | Татарстан Республикасы | СМ | 2021 | РБ | - | - | - | - | - | 329,760 | - | - | 329,760 |
| 1.5 | Биектау муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар | СМ, ЯЭСБ | 2021 | ҖБ | - | - | - | - | - | 3,2976 | - | - | 3,2976 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итүгә, физкультура-савыктыру һәм спорт рәсми чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга һәм спорт төрләре буенча спорт әзерлегенә муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча муниципаль йөкләмәләрне муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс белән тәэмин итү максатларында, күрсәтелгән учреждениеләрдә шөгыльләнүче спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләр күрсәтүгә бәйле чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бюджетара трансфертлар бирү | | | | | | | | | | | | |
| 1.6 | Биектау муниципаль районы бюджетына | СМ | 2021 | РБ | - | - | - | - | - | 4571,5 | - | - | 4571,5 |
| 1.7 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, физкультура-савыктыру һәм спорт рәсми чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга, түбә астындагы йөзү бассейнының оператив идарәсе хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль | СМ, ЯЭСБ | 2021 | ҖБ | - | - | - | - | - | 45,715 | - | - | 45,715 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләме арту өлешендә, башка бюджетара трансферлар бирү | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | БАРЛЫГЫ | 51934,3196 | 46341,547 | 46751,547 | 145027,4136 |